## 4. Бәхетле балачак

Гөмернең иң гүзәл мизгеле,
Тормышның борчусыз шук чагы.
Бу илдә гел кояш,
Бу илдә гел җылы,
Бу илдә әниең кочагы.
Кушымта: Бәхетле балачак
Хәтердә калачак,
Ияреп барачак гөмергә.
Бәхетле балачак
Хәтердә калачак.
Ул чаклар гел яшәр күңелдә.
Һәр мизгел кадерле бу чорда,
Сүтелә балачак сукмагы.
Шул сукмак буенча,
Шул сукмак эзеннән,
Үрелә киләчәк юллары.
Кушымта.
Балачак иленнән сәламнәр
Җиткерәбез сезгә, алыгыз.
Тик еллар үтсә дә,
Гомерләр үтсә дә,
Без бала күңелендә барыбыз.